КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 сентябрь г.Казань № 1066

Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны бер көнгә бер белем алучыга 2024 елга – 66,76 сум, 2025 елга – 69,43 сум, 2026 елга – 72,21 сум күләмендә;

башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен 2024 елга – 66,76 сум, 2025 елга – 69,43 сум, 2026 елга – 72,21 сум күләмендә.

2. Җирле үзидарә органнарына муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны бер көнгә бер белем алучыга билгеләү буенча шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган

мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында» 2022 ел, 14 сентябрь, 991 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында» 2022 ел, 14 сентябрь, 991 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 3 октябрь, 1065 нче.

4. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин